РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«29» сентябрь 2025ел

№ 134

2026 елга Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2025 елның 10 сентябрендәге 01/1511 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны кушымта нигезендә расларга.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 09 2025 № 134
карарына кушымта

2026 елга Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу урыны | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Авыл җирлеге | 137122 |
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | Авыл җирлеге | 209941 |